| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 август № 530

г. Казань

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеге мониторингы турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасы объектлары эшчәнлеген оптимальләштерү, нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ачык булуын тәэмин итү максатларында һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – ярдәм алучылар реестрын алып бару хакындагы һәм әлеге реестрлардан файдалануны технологик, программа, лингвистик, хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү чараларына таләпләр хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 ел, 6 май, 358 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын (алга таба – Система) төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеге мониторингы турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә документларны кабул итү һәм карап тикшерүнең бердәм стандартын.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Системаның дәүләт заказчысы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләнә;

Системаның функциональ операторы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләнә;

Системаның техник операторы вәкаләтләре «Татарстан Республикасының мәгълүмати технологияләр үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә йөкләнә.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә 60 көн эчендә Системаны төзүгә техник таләпләрне эшләргә;

2017 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының «Җиһазлар лизингын үстерү: КУЭ субъектлары чыгымнарын субсидияләү («Лизинг-грант»)», «Микрозаемнар бирү механизмнарын үстерү», «Җиһазлар сатып алуга чыгымнарны субсидияләү» чаралары кысаларында бирелә торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары буенча Системаны эксплуатациягә кертүне тәэмин итәргә;

2017 елның 1 маеннан Системаны кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүнең башка чаралары буенча эксплуатациягә кертергә.

5. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме чаралары күрсәтүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2017 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының элегрәк кабул ителгән хокукый актларын әлеге карарга туры китерү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков